# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге  Үчәлле авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18.10.2024  ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 18 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2025 елда,  Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум  күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-Үчәлле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (тракторчы белән техниканы арендалау, сыйдырышлылыкны арендалау; янгын гидрантларын тоту);

-Үчәлле торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамы һәм Тукай урамы асфальт-бетон юлларының чокырларын ремонтлау);

- Үчәлле торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

- Үчәлле торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү; үлән чабу, территорияне чистарту һәм чүп җыю буенча хезмәтләр)?

ӘЙЕ КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы  катнашучылар исемлегендә 188 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар  саны - 131 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен 131,
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2025 елда, Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

-Үчәлле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (тракторчы белән техниканы арендалау, сыйдырышлылыкны арендалау; янгын гидрантларын тоту);

-Үчәлле торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамы һәм Тукай урамы асфальт-бетон юлларының чокырларын ремонтлау);

- Үчәлле торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү);

- Үчәлле торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү; үлән чабу, территорияне чистарту һәм чүп җыю буенча хезмәтләр).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина